ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 461 от «22» 11 2023 г.

Татарстан Республикасы Мамадыш
муниципаль районы Башкарма комитетының
2022 елның 12 маендагы «Мәктәпкәчә төп
гомуми белем бирү программасын гамәлгә
ашыручы мәгариф учреждениеләрендә
балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» буенча муниципаль
хезмәт күрсәтүнең административ регламентын
яңа редакциядә раслау турында» 138 нче карарына
үзгәрешләр кертү турында

Социаль ярдәм чараларын күрү максатларында, Россия Мәгариф министрлыгының 2020 елның 2 сентябрендәге 458 нче номерлы боерыгы, Мамадыш муниципаль районы турындагы Нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 12 маендагы «Мәктәпкәчә төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф учреждениеләрендә балаларны исәпкә кую һәм кабул итү» буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын яңа редакциядә раслау турында» 138 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

II бүлекнең 2.7 пунктында түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

- «Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләре турында» 2016 елның 3 июлендәге 226-ФЗ номерлы Федераль законның 28.1 статьясы нигезендә махсус хәрби операциядә бурычларны үтәгәндә, яисә күрсәтелгән чордан соңрак үлгән (вафат булган), әмма махсус хәрби операция барышында бурычларны үтәгәндә алган гариплек (яралану, травма, контузия) яки авыру нәтиҗәсендә; шул исәптән тәрбиягә алган гаиләне дә кертеп, тәрбиягә алынган (кызлыкка) яисә опекага алынган, йә Россия Федерациясе субъектлары законнарында каралган очракларда патронат гаиләне дә кертеп, аларның гаиләләренең яшәү урыны буенча дәүләт һәм муниципаль гомуми белем бирү һәм мәктәпкәчә мәгариф оешмаларында чираттан тыш урыннар, шулай ук җәйге савыктыру лагерьларында урыннар бирелә».

2. Әлеге карар 2023 елның 7 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Н.Ш. Фатыйховка йөкләргә.

Җитәкче О.Н.Павлов